СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 1-49 от 06.02.2020г

# Об отчете Главы Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района о результатах своей деятельности и деятельности Исполнительного комитета, Совета Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района в 2019 году и задачах на 2020 год

Заслушав и обсудив представленный Главой Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района Крешкова И.П.отчет о результатах своей деятельности и деятельности Исполнительного комитета, Совета Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района в 2019 году и задачах на 2020 год, в том числе о решении вопросов, поставленных Советом Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района, в соответствии с Федеральным законом от 06.10.2003 №131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 28.07.2004 года №45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», Уставом муниципального образования «Албайское сельское поселение» Мамадышского муниципального района Республики Татарстан, Совет Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района Республики Татарстан р е ш и л:

1.Утвердить отчет Главы Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района о результатах своей деятельности и деятельности Исполнительного комитета, Совета Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района в 2019 году и задачах на 2020 год.

2. Признать деятельность Главы Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района и деятельность Исполнительного комитета, Совета Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района в 2019 году, том числе по решению вопросов, поставленных Советом Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района, удовлетворительной.

2. Депутатам Совета Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района довести отчет Главы Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района до сведения избирателей в своих округах.

3. Рекомендовать Исполнительному комитету Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района:

- разработать план мероприятий по выполнению замечаний и предложений,

высказанных в отчетном докладе и при его обсуждении, и информировать депутатов в срок до 1 марта 2020 года;

- принять меры для обеспечения развития предпринимательства во всех отраслях экономики Поселения;

- обеспечить повышение качества жизни населения на основе устойчивого, динамичного развития экономики и создания благополучной среды для граждан;

-обеспечить развитие личных подсобных хозяйств в населенных пунктах района, реализацию программ по строительству семейных ферм;

- совместно с правоохранительными органами вести дальнейшую работу по повышению уровня общественной безопасности, жизни, здоровья и достоинства граждан, частной, государственной и муниципальной собственности с максимальным использованием местного потенциала;

- продолжить мероприятия по благоустройству, озеленению и санитарной очистке населенных пунктов, обеспечению экологической безопасности;

4. Опубликовать отчетный доклад Главы Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района на информационных стендах поселения и разместить на официальном сайте Мамадышского муниципального района РТ в информационно-телекоммуникационной сети Интернет по веб-адресу: http://mamadysh.tatarstan.ru.

5. Контроль за исполнением настоящего решения возложить на Главу Албайского сельского поселения Мамадышского муниципального района Крешкова И.П.

Глава,
председатель Совета
Албайского сельского поселения
Мамадышского муниципального района Крешков И.П.

СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛБАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1626001355

**Албай авыл җирлегендә район хакимияте,**

**оешма җитәкчеләре белән очрашу**

**2019 нче ел йомгаклары буенча отчет**

**31 январь 2020 ел.**

Хәерле кич, хөрмәтле Ришат Робертович , учреждение һәм оешма җитәкчеләре, депутатлар, авылдашлар. җыелышта катнашучы иптәшләр! Рөхсәт итегез сезне Албай авыл җирлегендә 2019 нче елда башкарылган эшләр һәм 2020 нчы елга планнар белән кыскача таныштырып узарга.

Албай авыл җирлеге Советы, үзенең эшчәнлеген, Албай авыл җирлеге Уставына, Совет Регламентына һәм 2019 нче елга төзелгән переспектив планга нигезләнеп эш итте.

Албай авыл җирлеге 4 авылны берләштерә. Албай, Югары Әрнәш,Түбән Әрнәш, Зур Арташ. Авыл жирлегендә барлыгы 191 йорт бар, шуның 128 сендә яшиләр, 39 йортта җәйге чорда кайтып яшиләр, 24 йорт буш.

Албай авыл җирлеге территориясендә 1 фельдшерлык пункты, Албай төп мәктәбе, 1 почта бүлекчәсе, Албай авылы мәдәният йорты, 1 авыл клубы, 1 балалар бакчасы, 1 библиотека, 3 шәхси кибет халыкка хезмәт күрсәтә.Түбән Әрнәш авылында кибет булмау сәбәпле килеп сату оештырылган. Кибетләр барсыда Миннеханов Рафаилнеке. Территориядә 1 чиркәү бар.

Албай авылында 69 хуҗалыкта 172 кеше (чынлыкта 125 ) , Югары Әрнәш авылында 29 хуҗалыкта 65 кеше (чынлыкта 43), Түбән Әрнәш авылында
9 хуҗалыкта 13 кеше( чынлыкта 11), Зур Арташ авылында 21 хуҗалыкта 54 кеше ( чынлыкта 37) яши. Барлыгы 304 кеше. Шуларның 220 сы чынлыкта да авылда яшәүчеләр, ә 84 е пропискада бездә торып шәһәрдә яшәүчеләр .

Авылда мәктәпкәчә яшьтә 4 бала, мәктәп яшендә 10 бала , 15 студент, 124 пенсионер, 9 эш яшендәге һәм 23 пенсия яшендәге төрле группада булган инвалидлар, 67 кеше эш яшендә.

67 кешенең 26 се бюджет оешмасында, 5 кеше авыл хужалыгы тармагында , 28 кеше торле тармакларда авыл жирлегендә эшли, 7 кеше эшләмәүчеләр.

Демографик яктан караганда 2019елда 1 бала туды. 2018 елда 9 кеше вафат булса, 2019 елда 2 кеше вафат булды. Вафат булучылар 2 се дэ пенсия яшендәге кешеләр. 2019 елда 1 кеше пропискага керсә, 8 кеше пропискадан төште.

Бүгенге көнгә авылда яшәүче халыкның күпчелек өлешен пенсия яшендәге халык тәшкил итә . 60-70 яшьтәге – 35 кеше, 70-80 яшьтәге -33 кеше, 80-90 яшьтәге – 31 кеше, 90 яшьтән өлкән 5 кеше яши.

**2019 елның эш нәтиҗәләренә йомгак ясарга керешкәндә иң беренче итеп еллык бюджетның үтәлешенә тукталып узыйк.**

**( бюджет үтәлешен таблицада күренә)**

Һәр календарь яңа ел башланыр алдыннан, авыл җирлеге бюджетын формалаштыру һәм раслау уздырыла.

Расланган бюджет нәтиҗәсендә, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне исәпкә алып, аның 2019 нчы елга керем (доход) ягы – 3мл 356мен сумны тәшкил итте.

Шулай ук 2019 нчы елга үз керемнәребез 2мл 448900 сум керүне планлаштырган идек.

Үз керемнәребез (собственные доходы) түбәндәге налог керемнәреннән төзелде:

- Физик затларның керемнәренә налог – 26 300 сумны,
- Шулай ук физик затларның мөлкәт өчен булган налогы – 15000сумны,
- Җир налогы – 210 000 сумны,
- Үзара салым-874 00сумны
- Төрле керемнәр өчен – 87 200 сумны
- Район финанс яклау фонды дотациясе – 2млн. 945100 сумны тәшкил итә.

Бюджет узкеремнәребез 3мл 380мен сум . Бюджет 2019 нче елга 100,7 % ка үтәлде.

Авыл җирлегендә 7 депутат исәпләнә. 2018 елда барлыгы 11 утырыш уздырылды, анда 38 сорау каралды.

Үзебезнең рәсми сайтыбыз да бар. Сайтта Бюджет, Совет эшчәнлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне оештыру турындагы магълүмәтләрне, җирле үзидәрә органнары кабул итә торган норматив-хокуки актларны, шулай ук публичный тыңлаулар узуы турындагы мәгълуматлар һәм ничек узуы турындагы нәтиҗәләр урнаштырылып барыла. Теләге булган һәр кешенең дә моның белән танышып бару мөмкинлеге бар.

Һәр җирлек, һәр авыл үз проблемалары һәм уз тәртибе белән яши. Җирлектә яшәүче халык тырыш: мал –туар асрый, умарта тота, балта эшләре, алып-сату белән шөгыльләнә. Халык үз тырышлыгы белән тормышын алып бара, акчаны эшләп таба белә.

Территориядәге шәхси хуҗалыкларда барлыгы 118 баш мөгезле эре терлек, шул исәптән 53 баш савым сыер, 141 баш сарык һәм 90 кәҗә, 2 баш ат, 678 тавык, 140 баш умарта асрала. Җәй көне терлекләр 3 авылда электрокөтүлектә йөри. 3 электрокөтүлегебез бар.

Хуҗалыклар үзләреннән арткан сөтне хөкүмәткә тапшыралар. Бу иң беренче чиратта, аларның үзләренең гаилә бюджетларын тулыландыруның мөһим чыганагы булып тора.

2019 елда иң күп сөт тапшыручы гаиләләрне атап үтәсе килә. Боларга Зур Арташтан Сергеев Геннадий-12340 л, Албайдан Малов Алексей-9374 л, Гайнетдинов Фанил -8643 л, Югары Әрнәштән Дмитриев Петр 4100 л гаиләләре керә.

2019 елда авыл җирендә сыер асраучы хуҗалыкларга 1 сыер башына 1 сыер асраучыларга 2000 сум, 2 сыер асраучыларга 3000 сум, 3 һәм аннан күбрәк сыер асраучыларга 4000 сумнан ,1 кәҗә башына 500 сум

күләмендә субсидия бирелде, барлыгы халыкка 192500 мең сум акча өләшенде. Халык җитәрлек күләмдә печән белән тәэмин ителде. Үзебезнең 50 гектар басуыбыз бар. Печән кирәк булган һәркем шул басудан үзенә кирәк кадәр печән алды. Пай җирләренең хуҗалары белән ООО " Агроинпекс" арасында 300 кеше белән договор төзелгән. Договор нигезендә 1 пай җиренә 2000 сум акча түләү каралган. Авылларыбызда яшәүче халыкның тормыш-көнкүреше елдан ел яхшыра бара. Без моны территориядә яшәүче хуҗалыкларда яңадан-яңа төзелешләр алып барылуда, машина, тракторлар саны артуда , йортлар ремонтлануда күрәбез.

Көченнән килә торган кеше мал асрап яши. Фермерларыбыз булмаса да авылларыбызда бүген аягында нык басып торган хуҗалыкларыбыз бар. Җирлектә 2-3-6 ар баш савым сыер тотучы хужалыкларыбыз да бар. Боларга 6 сыер асраучы- 2 хуҗалык ( Сергеев Г., Краснов М.), 3 сыер асраучы- ( Гайнетдинов Ф) 2 сыр асраучы – 4 хуҗалык ( Савельев С.,Григорьев Н., Мишурин П.,Сармаков Н.) керә.

Авылда хуҗалыкларда трактор, йөк машинасы , җиңел машиналарның булуы хуҗалыкларга мул итеп терлек азыгы хәзерләү өчен тулы шартлар тудыра. Албай авыл җирлегендә эшче яшендәге тулы гаиләләр Албайда -18 , Зур Арташта -4 , Түбән Әрнәштә -1 , Югары Әрнәштә -7 . Барлыгы 30 гаилә. Бу 30 гаиләнең 28 зе сыер һәм мөгезле эре терлек тота. Пенсия яшендә булып та мөгезле эре терлек асраучы 6 хуҗалык исәпләнә.

Авылда умартачылык гаилә бюджетына иң зур керем кертүче тармак. 10-15 гаилә умартачылык белән шөгыльләнә, умартаны керем чыганагы буларак тота. Назаров Сергей, Семенов Иван, Сергеев Геннадий һ.б. әлеге тармактан продукция җитештереп шактый зур табыш ала.

Малларга прививкалар ясау, анализга кан алу кебек барлык ветеринария чаралары вакытында үткәрелеп бара. Бу вакытында маллардагы авыруларны ачыкларга һәм кичектерергә ярдәм итә. 2019 елда мөгезле эре терлекләрдәге лейкоз авыруы авыллардагы 1 баш савым сыерда булуы ачыкланды.

Белгәнегезчә 2014 нче елдан халыктан үзара салым җыю оештырылган иде. Һәрберебезгә мәгълүм булганча үзара салым җыю акчасының авыл җирлекләрен тәртиптә тоту, халыкның көнкүреш тормышын яхшырту өчен күп файда китергәнен һәр елны шул акча хисабына башкарылган эшләребез раслый. 2014 елда халыктан (бер кешегә 200 сумнан) 54700 сум күләмдә акча җыелды, һәм бу акча дәүләт ярдәме белән 218800 сумга тулыландырып 273500 сум күләмдә авыл җирлегендә урнашкан 3 зиратны ремонтлау өчен тотылды. 2015 елда халыктан( бер кешегә 200 сумнан) 54000 сум күләмдә акча җыелды һәм бу акча дәүләт ярдәме белән 216000 сумга тулыландырып 270000 сум күләмдә авыл җирлегендә урнашкан 3 күперләрне ремонтлау өчен кулланылды. 2016 елда халыктан ( бер кешегә 200 сумнан) 52 мең сум күләмендә акча җыелды. Президент ярдәме белән барлыгы 260 мең сум акча тупланды. Бу акчаларга барлык авылларда икешәр чишмә ремонтланды, койма белән әйләндереп алынды. 2017 нче елда халыктан( бер кешегә 300 сумнан) 74700 сум күләмдә акча җыелды. . Җыелган акчаның 1сумына Республикадан 5 тапкыр артырылып 373500 мең сум тәшкил итә. Бу акчаларга барлык авылларда да урамнарга барлыгы 96 данә диотный лампалар урнаштырылды, релеләр, счетчиклар куелды. Бу урында диотлы лампаларны урнаштыруның файдасының бик зур икәнлеген әйтеп китәсе

килә. Моны түбәндәге саннарда күрергә була. 2019 елда  бары 15013 киловатт электр энергиясе кулланып аның өчен 96808,27 тиен акча түләнгән. Бу 2018 ел белән чагыштырганда 300000 сум акчаны  экономияләргә ярдәм иткән дигән сүз. 2019 нче елда халыктан( бер кешегә 400 сумнан) барлыгы 87400 акча жыелды , дәүләт  ярдәме белән ул сумма 5 тапкыр артырылып 437000 сум тәшкил итте.

2018 елда җыелган  үзара салым акчасына: Албай  авылында  4 штук , Югары Әрнәш авылында 2 штук пожарный гидрантлар сатып алынды һәм урнаштырылды. Шулай ук Албай авылында  су тутыру емкасте алыштырылды,ә Югары Әрнәш авылында су кудыру башнясы ремонтланды һәм ике авылныкында  рәшәткә белән әйләндереп алынды. Зур Арташ һәм Түбән Әрнәш авыллары арасында урнашкан күпер ремонтланды.

2019 нчы елда жыелган узара салым акчасы Албай авылында зиратка баручы юлга, Верхний Эрнэш авылында Максимов урамына юлга таш жэюгэ тотылды.

2019 елнын ноябрь аенда референдум урынына авылларда  салым жыю турында  жыелышлар  үткәрелде. Жыелыш нәтиҗәләре буенча  2020 ел өчен узара салым акчасын  һәр кешедән  400 сумнан җыю каралды.

Бу жыелган акчалар Албай авылында зират юлын, Верхний Эрнэш авылында Максимов урамына таш жэюне тогэллэргэ  каралды. Югары Арташ авылыннан жыелган акча юл тигезлэу хэм кардан  чистарту очен каралды.

Шәхси хуҗалыкларда төзелеш, агымдагы ремонт эшләре уздырылып тора, йорт яннары тәртиптә тотыла.  Юлларның матур, тигез булуы  авылга ямь өсти. Җирлек территориясендә санитария кагыйдәләренең үтәлешенә килгәндә, яз аена  керүгә, авыл жирлеге тарафыннан һәр хуҗалыкка урамнарда, тыкырыкларда, бакча артларында  тәртип булдыру, җыештыру һәм тәртипкә китерү эшләре кисәтелә. Чисталык икеайлыгында яки апрель, май айларында җирлеккә кергән һәр оешма, мәктәп укучылары актив катнашты, юл кырыйлары чүпләрдән, чүп үләннәреннән чистартылып торды, баганалар агартылды. Май аенда Зур Арташ зиратында өмә үткәрелеп чүп – чардан чистартылса, июль аенда Югары Әршәш һәм Албай зиратлары печәннән чистартылды. Һәр елны да, җирлектә территорияне яшелләндерү максаты белән агачлар утыртыла. Бу эштә учреждениеләр актив катнаша  . Шулай ук җирлектәге барлык оешма учреждениеләр дә, күп кенә шәхси хуҗалыклар җәй көннәрендә матур итеп чәчәкләр үстерәләр. Авылыбыз урамнарын, тирә якны чистарту, тәртиптә тоту барыбыз өчен дә бурыч һәркем җаваплылык тоярга тиеш. Бюджет  хезмәткәрләре авыл җирлеген төзекләндерүдә актив катнашалар. Яз көз көннәрнендә чисталык буенча өмәләр үткәреп килдек, зиратларны чистарту, юл кырыйларындагы чүпләрне җыю, социаль объект  территорияләрен чистартуны оештырдык.  Кышкы чорда авылларда юллар кардан даими чистартылып тора, бу эшләрне башкарыр очен  авыл советының МТЗ 82 тракторы һәм Семенов Михаилның ДТ тракторы һәр даим ярдәмгә килә.

Албай авыл җирлеге халыкны социаль яклау буенча эш алып бара. Барлык ялгыз карт һәм ярдәмгә мохтаҗ  кешеләр хисапка алынган. Кызганыч, җирлектә бүгенге көндә исән сугыш ветераннарыбыз инде юк, 2 ветераннарнын тыл хатыннары, 15 тыл ветераны яши. Билгеле булганча 9

май көнне Геройлар аллеясы янында Бөек Җиңүнең 74 еллыгын билгеләп үттек. Депутатыбыз Гайнуллин Ильшат Шавкатович ветераннарга ашамлык пакетлары таратты, шулай ук бәйрәм уңаеннан мәктәпләрдә, клубларда төрле мәдәни чаралар уздырылды. Ел дәвамында мәдәният йортында төрле концертлар, тамашалар, тематик кичәләр булды. Авылыбызның күркәм кешеләрен искә алу, юбилей кичәләрен үткәрү матур гадәткә керде. Авылыбызның яшьләре төрле чараларда актив катнашалар, каникулларда студентлар белән очрашулар ,концертлар оештырыла , алар шулай ук укыган җирләрендә дә сынатмыйлар, чараларда, конкурс-ярышларда алдынгылар. Питрау бәйрәме авылда күмәк көч белән үткәрелә. Бу чараларда спонсорларыбыз Яруллин Ахат Нуриеевич, Гайнуллин Ильшат Шавкатовичлар зур ярдәм итә. Яна елга ике депутатыбыз да балаларга яна ел пакетлары олэштелэр.

**1 октябрь-** Өлкәннәр көне. Шул уңайдан авыл жирлеге өлкәннәргә азык-төлек пакетлары таратылды. Бу пакетларга акчаны шулай ук депутатларыбыз Гайнуллин Ильшат Шавкатович, Яруллин Ахат Нуриевичлар бирде. Мәктәп һәм клуб хезмәткәрләре тарафыннан чәй эчүләр һәм концертлар елдагыча бик актив оештырылды.

Һәр елны район үзәгендә һәм башкалабыз Казанда үткәрелә торган ярминкәләрдә авыл җирлегебез актив катнаша. Хуҗалыкларда җитештергән продукцияне сөт, ит, йомырка, каз-үрдәк, җиләк-җимеш, яшелчәләрне Казан, Мамадыш халкы бик яратып ала. Бу чараларда җирлектәге барлык учреждениеләр, мәктәп коллективы, балалар бакчасы, мәдәният хезмәткәрләре актив катнаша.

Авыл жирлегендә Усали врач амбулаториясенә караган 1 фельдшерлык пункты эшли. Авыл фельдшеры халыкка көндәлек хезмәт күрсәтә, Усали амбулаториясе врачлары үзләренен графиклары буенча профилактик эшләрен даими алып баралар. Республика буенча уздырыла торган диспанцсеризация оешкан төстә башкарыла. Бу медицина хезмәткәрләре һәм халыкның җаваплы, җитди каравын күрсәтә.

2019 елга алган планнар буенча эшлэгэн эшлэр.

1. Авыл советы зданиясенэ капиталь ремонт ясау иде. Бу эшне Мамадыш строй оешмасы 2 ай эчендэ башкарып чыкты.
2. Яна ФАП салынды. Яздан ук урынын тигезлэп су, канализация ясалды, июньдэ фундамент салынды. 1 ай эчендэ тозелеп тэ бетте.
3. Самоблажение акчасына июль аенда Албай авылында зират ягына баручы юлга 250м озынлыкка ком хэм таш жэелде, Верхний Арняш авылында Максимов урамы ягына баручы юлга 105м ком хэм таш жэелэ башлады.
4. 50 га тау кырыена агач утыртылды.

2020 нчы елга бурычлар, планнарга килгәндә, эшләребез күп. Албай авылы мәдәният йортына капиталь ремонт ясау . Албай авылында программа буенча 6 миллионлык Спорт площадкасы хэм балалар мәйданчыгы төзү планлаштырыла. Шулай ук 2020 елда үзара салым акчасы Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатында тотылачак. Бу акчага Албай торак пунктында зират ягына

баручы юлны, Югары Әрнәш торак пунктында Максимов урамы ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау, авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту максат итеп алына. Еллык планда булган барлык чараларны үткәрү. 8 май, Геройларның туганнарын чакырып Бөек җину көнен үткәрү, Питрау бәйрәме, өлкәннәр көнен билгеләп үтү, Яна ел бәйрәмнәрен үткәрү болар барысы да планга кертелгән. Шулай ук зиратларны, территорияләрне чистартып тору, агачлар утырту, кыш көне юлларны даими чистартып тору максат итеп алына. Иске ФАП зданиясендэ музей ясап 8 май көнне ачылу планлаштырыла.

Быел сентябрь аенда Татарстан президентын хэм авыл советына депутатлар салау була. Авыл советына 7 депутат сайланачак.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә, без авыл җирлегендә халык мәнфәгәтен, халык сорауларын алга куеп эшләргә тырышабыз, ләкин нәрсәгә тотынсак та район җитәкчелеге, төбәгебез җитәкчеләре, якташ иганәчеләребез белән берлектә, бергә көч куйганда гына зур нәтиҗәләргә ирешә алабыз.

Игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт Сезгә!